МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.05.2024 Казан ш № 389

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны алмаштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны алмаштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 02.09.2014 №476, 07.06.2016 №317, 24.07.2017 №503, 07.05.2018 №352, 18.09.2018 №858, 12.11.2019 №991, 06.04.2020 №228, 13.07.2020 №499, 09.10.2020 №717, 18.06.2021 №432, 01.10.2021 №708, 11.04.2022 №266, 24.06.2022 №622, 28.08.2023 №702 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2024 елның «29» маендагы 389 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны алмаштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерыкның атамасында «(Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны алмаштыру)» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алыштырырга;

боерыкның 1 пунктында «(Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны алмаштыру)» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны алмаштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

атамасында «(Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны алмаштыру)» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алыштырырга;

1.1 пунктында «(Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны алмаштыру)» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алыштырырга;

1 нче бүлекнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Мөрәҗәгать итүче – Татарстан Республикасында яшәүче (торучы) күпбалалы гаиләнең ата-аналарының берсе, анда ким дигәндә өч баланың Татарстан Республикасында яшәү (тору) урыны булырга тиеш (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен законлы вәкилләр яки билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле затлар тәкъдим итә ала.»;

2 бүлектә:

2.1 пунктында «(Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны алмаштыру)» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алыштырырга;

2.2.1 пунктта «гаиләнең фактик яшәү урыны буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны яки тору урыны буенча» сүзләре белән алмаштырырга.»;

2.3.1 пунктында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар тора.»;

икенче абзацта «таныклык (таныклык дубликатын) бирү (озайту) турында (бирүдән (озайтудан) баш тарту)» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында» сүзләре белән алмаштырырга;

2.3.2 пунктында:

беренче абзацта «таныклык (таныклык дубликатын) бирү (озайту) турында (бирүдән (озайтудан) баш тарту)» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында» сүзләре белән алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«язма рәвештә – шәхсән яки почта адресы буенча;»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«электрон документ формасында – электрон почта адресы һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталындагы (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы (https://uslugi.tatarstan.ru/) шәхси кабинетына.»;

2.3.4 пунктында:

беренче абзацта «таныклыкны (таныклыкның дубликатын) бирү (озайту) турында» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында» сүзләре белән алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «таныклык (таныклык дубликаты) бирүдә (озайтуда)» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләүдән баш тартуда» сүзләре белән алмаштырырга;

унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

ундүртенче абзацта «таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән (озайтудан)» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләүдән» сүзләре белән алмаштырырга;

2.4.2 пунктта «таныклык (таныклык дубликатын) бирү (озайту) турында (бирүдән (озайтудан) баш тарту)» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында» сүзләре белән алмаштырырга;

2.4.4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга:

2.6.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Күпбалалы гаилә статусын билгеләү өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) тапшырыла торган документлар:

1. Күпбалалы гаилә статусын билгеләү өчен мөрәҗәгать итүче тапшыра (җибәрә):

1) гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы һәм Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында һәм Бердәм порталда, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән), әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап;

2) баланың тууын теркәү турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

3) өйләнешү турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

4) аерылышу турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

5) чит ил территориясендә бирелгән Россия Федерациясеннән читтә уку турында документ һәм аның рус теленә нотариаль расланган тәрҗемәсе;

6) Административ регламентка 11 нче кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык һәм тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк булса һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә мондый шәхси белешмәләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән башкарылган очракта, мөрәҗәгать итүче булып тормаган зат тарафыннан бирелә, күрсәтелгән зат хәбәрсез югалган дип танылган яисә эзләнүгә игълан ителгән һәм аның урнашу урыны вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнмәгән очраклардан тыш);

Ата-аналарның берсе хәбәрсез югалган дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә әлеге ата-ананы хәбәрсез югалган дип тану турында суд карарын тәкъдим итә.

7) ир белән хатын аерылышкан очракта, баланың (балаларның) яшәү урынын билгеләү турында законлы көченә кергән суд карары күчермәсе;

8) көндезге уку формасы буенча белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмада 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы укыту факты турында белешмә.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар өстәмә рәвештә аларның вәкаләтләрен раслаучы документны тәкъдим итәләр.

Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм портал аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклый торган документындагы белешмәләре исәпкә алыну язуы Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – БИАС) расланган вакытта тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә бирелгән юридик зат тарафыннан бирелгән вәкаләтле затның вәкаләтләрен раслый торган документ документны биргән вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен раслый торган, шәхси эшкуар тарафыннан электрон рәвештә бирелгән документ шәхси эшкуарның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә бирелгән нотариус тарафыннан бирелгән вәкаләтле затның вәкаләтләрен раслый торган документ документны биргән нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана. Башка очракларда – гади электрон имза белән имзаланган булырга

тиеш.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:

1) Идарәгә (бүлеккә) шәхсән кәгазьдә;

2) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша электрон формада;

3) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша;

4) КФҮ аша;

2) почта аша җибәрү юлы белән;

Документларның күчермәләре, әгәр дә алар законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече яисә күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза шулай ук Идарәдә (бүлектә) белгеч тарафыннан шәхсән кабул ителгәндә электрон рәвештә дә тутырылырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон язуларны укый торган җайланмадан файдаланып имзалый.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә), КФҮ шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында http://mtsz.tatarstan.ru урнаштырылган.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.»;

2.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

бала туу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

өйләнешү (аерылышу) турында (Федераль салым хезмәтеннән);

мөрәҗәгать итүченең һәм балаларның Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны буенча теркәлү булу-булмавы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында (җирле үзидарә органнарыннан);

18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы гомуми белем бирү оешмасында укыту турында (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгыннан);

гражданин паспортының чынлыгы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Югарыда аталган белешмәләрне үз эченә алган әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.»;

2.8.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;Р59

2) дөрес булмаган мәгълүматлары булган документлар тапшырылган очракта;

3) мөрәҗәгать итүченең һәм өч баланың Татарстан Республикасы территориясендә яшәү (тору) урыны булмавы;

4) мөрәҗәгать итүче тәкъдим иткән документларның формасы яки эчтәлеге буенча әлеге Регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

5) Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указына ярашлы рәвештә билгеләнгән күпбалалы гаилә статусы турында мәгълүмат булу;

6) мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гаиләсе әгъзаларының Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү тәртибе турында» 29.05.2024 №388 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү тәртибенең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве (алга таба – 388 номерлы тәртип):

күпбалалы гаилә составында, күп балалы гаиләнең барлык әгъзалары Россия Федерациясе гражданнары булу шарты белән, фактта яшәүче һәм 18 яшькә кадәрге һәм (яки), белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку формасы буенча белем алу шарты белән, 23 яшькә кадәрге, шул исәптән тәрбиягә алынган (уллыкка алынган) балаларын, үги ул-кызларын тәрбияләүче ир белән хатын, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада укулары белән бәйле рәвештә, ата-аналардан аерым яшәүче балаларның күрсәтелгән категорияләре исәпкә алына;

7) 388 номерлы тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән шартларның булуы:

ата-аналары яки бердәнбер ата-анасы ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балалар;

эмансипация яки гаилә кору сәбәпле тулы күләмдә эшкә сәләтле балалар.».

3 бүлектә:

3.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны тутыру өлешендә дә;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү»;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны (алга таба – техник хата) төзәтү.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Идарә (бүлек) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затлары яки дәүләт граждан хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу, авторизацияләнү шарты белән, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетта гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта үз инициативасы буенча шәхси кабинетта электрон гаризаның статусын, шулай ук алга таба башкарылачак гамәлләр турында мәгълүмат карау мөмкинлегенә ия.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты турындагы белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында уңай карар кабул ителүе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе алу мөмкинлеге турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезле баш тарту була.

в) күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар җибәрелә.»;

3.3.1 пунктның беренче абзацында «таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында» сүзләре белән алмаштырырга, «2.5 пунктта» сүзләрен «2.6.1 пунктта» сүзләре белән алмаштырырга;

3.3.1.1 пунктның беренче абзацында «2.5 пунктта» сүзләрен «2.6.1 пунктта» сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.2 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

3.4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.3. Идарә (бүлек) белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша вәкаләтле органнардан түбәндәге мәгълүматларны соратып ала:

бала туу турында (Федераль салым хезмәтендә);

өйләнешү (аерылышу) турында (Федераль салым хезмәтендә);

мөрәҗәгать итүченең һәм балаларның Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны буенча теркәлү булу-булмавы турында  (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгында);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында (җирле үзидарә органнарында);

18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы гомуми белем бирү оешмасында укыту турында (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгында);

гражданин паспортының чынлыгы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгында).

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

түбәндәге эчтәлектәге 3.4.4 пункты белән тулыландырырга:

«3.4.4. Әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның 7.2 статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедура нәтиҗәсе: сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы мәгълүматларны) алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»

3.5 пунктта «таныклык (таныклык дубликатын) бирү (озайту) турында» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Идарә (бүлек) белгече әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган белешмәләр нигезендә һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:»;

икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче һәм алтынчы абзацларда «таныклык (таныклык дубликатын) бирү турында (бирүдән баш тарту)» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.2 пунктта:

беренче-икенче абзацларда «таныклык (таныклык дубликатын) бирү турында (бирүдән баш тарту)» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында» сүзләре белән алмаштырырга;

өченче абзацта «таныклык (таныклык дубликатын) бирү (озайту) турында (бирүдән (озайтудан) баш тарту)» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3. Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында телефонга СМС-хәбәр белән хәбәр итә. Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (язма рәвештә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча

электрон документ рәвешендә, шәхси кабинет аша Бердәм порталда яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, шәхсән) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар имзаланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү .»;

3.5.4-3.5.6 пунктлары үз көчләрен югалткан дип танырга;

3.6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник хатаны төзәтү мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентка 5 нче кушымта нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны теркәп, күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарда техник хатаны төзәтү турында гариза бирелгән очракта гамәлгә ашырыла.»;

өченче абзацта «таныклык (таныклык дубликатын) бирү (озайту) турында» сүзләрен «күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында» сүзләре белән алмаштырырга;

алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

3.6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Идарә (бүлек) белгече:

техник хатаны төзәтү турынданы гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын яңадан рәсмиләштерә;

күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарның яңадан рәсмиләштерелгән проектын Идарә (бүлек) җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, Идарә (бүлек) җитәкчесенә кул кую өчен җибәрелгән күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар проекты.»;

3.6.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.3. Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, яисә Бердәм порталда яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карарны җибәрү юлы белән) күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карарны юллый).

Бу пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә күпбалалы гаилә статусын

билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү, күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карарның күчермәсен Бердәм порталда яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрү.»;

3.6.4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлегенә)

________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Гариза №____

________________ 20__ ел.

Мин, ________________________________________________________________,
(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), тулысынча)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

яши торган адрес:

______________________________________________________________________,
(индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)

эш итү нигезе:

________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый

торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат мөрәҗәгать иткән очракта)

Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры _____________

Күпбалалы гаилә статусын билгеләүне сорыйм _______________________________,

(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

_______________________________________________________________________

яши торган адрес: ______________________________________

_______________________________________________________________________

(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

_______________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең гаилә составы турында мәгълүмат:

| | (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (туган көне) | Паспорт (туу турында таныклык) реквизитлары | Туганлык дәрәҗәсе | Яшәү урыны яки тору урыны буенча теркәлүе | Бала көндезге уку формасы буенча белем алучы белем бирү оешмасының исеме [1] |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

[1] көндезге уку формасы буенча белем алучы белем бирү оешмасында укымый торган 18 яшьтән өлкәнрәк балалар күпбалалы гаилә составына кертелми.

Гариза бирү көненә түбәндәге расламаларның берсе яки берничә дөрес булып торса, тиешле шакмакка тамга куегыз:

гаилә составына кергән балаларга карата Сез ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән;

гаилә составына керә торган балалар өйләнешү яки эмансипаци сәбәпле эшкә сәләт алмаган.

Күпбалалы гаиләнең яшәү адресы: _____________________

_______________________________________________________________________

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм айлык пособие түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым ________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең яки ышанычлы затның имзасы)

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза:

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп _________________________

(телефон номеры)

Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар алуга риза:

почта адресы буенча язма рәвештә____________________________

______________________электрон почта адресы буенча

(электрон почта адресы)

шәхси кабинет аша

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ______________________________

(«әйе» яки «юк» дип күрсәтергә)

шәхсән_________________________________________

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ _________ ________________

(дата, белгечнең имзасы, тулы имзасы)

_____________________________________________________________________

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры ____

Документлар саны ______ данә, __ биттә

Документларны кабул итте ___________ _________ ________________ ____________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 1[1] кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1[1] кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлегенә)

_____________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Персональ белешмәләрне эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

Мин, ______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

теркәлгән адрес ____________________________________________________
______________________________________________________________________
паспорт сериясе _______ №_________________ бирелгән _________________________

______________________________________________________________,
«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) аша түбәндәге персональ белешмәләремне эшкәртүгә (теләсә нинди гамәл (операция) яки автоматлаштыру чараларын файдаланып яисә мондый чараларны файдаланмыйча гына кылына торган гамәлләр (операцияләр) җыелмасын башкаруга, шул исәптән җыю, яздыру, системага салу, туплау, саклау, тәгаенләштерү (яңарту, үзгәртү), алу, куллану, тапшыру (тарату, бирү, файдалану), шәхси булуын бетерү, файдалана алмаслык итеп чикләп кую, бетерү, юкка чыгару өчен ризалык бирәм:

фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), шул исәптән, үзгәртелгән очракта, алдагы фамилияләр, исемнәр һәм (яки) ата исемнәре;

телефон номеры, электрон почта адресы яки почта адресы;

яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлү адресы, фактта яшәү адресы;

паспорт белешмәләре (төре, сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән);

гражданлык хәле актларын теркәү турында таныклык реквизитлары;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен эшкәртелүе таләп ителә торган башка шәхси мәгълүматлар.

Югарыда күрсәтелгән персональ белешмәләрны миңа карата Россия Федерациясе законнары үтәлешен тәэмин итү максатларында эшкәртү өчен тапшырам.

Мин танышып чыктым:

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге килешүне имзалаганнан соң, мин тапшырган документларны саклау срогы чыкканчыга кадәр гамәлдә була;

персональ белешмәләрне эшкәртүгә бирелгән ризалык минем тарафтан ирекле рәвештә язылган гариза нигезендә кайтарып алынырга мөмкин;

персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалыкны кире алган очракта, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау

министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) аша «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясының 1 өлешендәге 2-11 пунктларында, 10 статьясының 2 өлешендә һәм 11 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр булганда персональ белешмәләрне эшкәртүне дәвам иттерергә хокуклы;

өченче затларга карата тапшылыра торган персональ белешмәләр бары тик Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) аша аңа йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында гына эшкәртеләчәк.

«__»________ 20__ ел.            ____________/________________________________

(имза)                    (тулы имза)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлегенә)

______________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,__________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

теркәлгән адрес ___________________________________________________

_____________________________________________________________________

паспорт сериясе ________ №___________ бирелгән _______________________________

_____________________________________________________________________,

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) аша (алга таба – оператор) (420044, Казан шәһәре, Волгоград урамы, 47 й.; ОГРН 1071690050299) күпбалалы гаилә статусын билгеләү максатында үземнең персональ белешмәләремне таратуга (тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге:

фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), шул исәптән, үзгәртелгән очракта, алдагы фамилияләр, исемнәр һәм (яки) ата исемнәре;

телефон номеры, электрон почта адресы яки почта адресы;

яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлү адресы, фактта яшәү адресы;

паспорт белешмәләре (төре, сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән);

гражданлык хәле актларын теркәү турында таныклык реквизитлары;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен эшкәртелүе таләп ителә торган башка шәхси мәгълүматлар.

Шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматлары оператор тарафыннан затларның чикләнмәгән даирәсенә тапшырылачак һәм алар белән башка төрле гамәлләр кылыначак мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://mtsz.tatarstan.ru//.

Мин танышып чыктым:

шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге килешүне имзалаганнан соң, мин тапшырган документларны саклау срогы чыкканчыга кадәр гамәлдә була;

шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык минем тарафтан ирекле рәвештә язылган гариза нигезендә кайтарып алынырга мөмкин;

персональ белешмәләр субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалыкны кире алган очракта, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) аша «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясының 1 өлешендәге 2-11 пунктларында, 10 статьясының 2 өлешендә һәм 11 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр булганда персональ белешмәләрне эшкәртүне дәвам иттерергә хокуклы;

өченче затларга карата тапшылыра торган персональ белешмәләр бары тик Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) аша аңа йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында гына эшкәртеләчәк.

«___» ________ 20__ ел.          _____________/______________________________

(имза)                    (тулы имза)»;

Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында гаризаларны теркәү журналы

| т/с | Мөрәҗәгать итү датасы | Мөрәҗәгать итүченең ФИА исеме (соңгысы – булган очракта) | Мөрәҗәгать итүченең адресы | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгать итү нәтиҗәләре | Гариза бирүчегә хәбәр итү ысулы (хәбәр итү датасы)»; |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Регламентка $2^1$ кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына $2^1$ кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар формасы

________________________________________
карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

________________________________________

________________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);
Мөрәҗәгать итүченең адресы

________________________________________
Гаризаның номеры һәм теркәү датасы

Карар
________/_________
___________ №______________

________________________________________________________________________
(башкарма хакимият органының исеме)

Гаризаны һәм тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча

____________________________________________________________________________
гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

____________________________________________________________________________
(гаризаның номеры һәм гаризаны теркәү датасы)

«Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү» дәүләт хезмәте күрсәтүдән, нигезе ____________________

____________________________________________________________________________
(хезмәт күрсәтүне җайга сала торган РФ субъекты норматив хокукый акты, аның номеры һәм датасы күрсәтелә)

___________ 20__ ел, ___________ №________ күпбалалы гаилә статусын билгеләү турындакарар кабул ителде.

_______________________________          ______________________________
Затның вазыйфасы,                                        (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)
карар кабул итүгә вәкаләтле

| Электрон имза сертификаты турында белешмәләр |
|---|

## Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән/хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар формасы

________________________________________
карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме
__________________________________

________________________________________
гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта), адресы

________________________________________
Гаризаның номеры һәм гаризаны теркәү датасы

Карар
___________/___________
___________ №____________

______________________________________________________________________________
(башкарма хакимият органының исеме)

Каралган гариза нәтиҗәләре буенча
______________________________________________________________________________
гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);
______________________________________________________________________________
(гаризаның номеры һәм гаризаны теркәү датасы)

«Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү» дәүләт хезмәте күрсәтүдә карар кабул ителде _______/_______, түбәндәге нигезләр буенча:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(баш тарту сәбәпләрен аңлату)

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез: ________________________________________
______________________________________________________________________________
(хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Баш тарту турындагы әлеге

карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

______________________________________________________________________

Затның вазыйфасы,
карарны кабул итүгә вәкаләтле Ф.И.А. (атасының исеме – булган очракта)

______________________ __________________

| Электрон имза сертификаты турында белешмәләр”; |
|---|

Регламентка 3 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында
күпбалалы гаилә статусын билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, _______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта) тулысынча)

яши торган адрес
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

______________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның исеме, аның сериясе, номеры,
бирелү датасы, документны биргән орган атамасы)

______________________________________________________________________,

техник хатаны төзәтүне сорыйм ______________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________,

күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар җибәрелә
___________________________________________.
(карар реквизитлары, бирелү датасы)

Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар алуга риза
______________________________________________________________________.
(язма рәвештә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, шәхси кабинетка Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, шәхсән)

«___»___________ 20__ел. ___________________ ____________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имзасы)».